**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**ТУРАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

09.02.2023 ел Менделеевск ш. № 75

"Җир салымы турында"
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге
Советының 2019 елның 13 декабрендәге
104 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге советының 2019 елның 13 декабрендәге 104 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 5 пунктын үзгәртергә һәм бәян итәргә: «салым түләүчеләргә – оешмаларга салым түләүнең агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталы узганнан соң җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасы ¼ күләмендә алдан түләнүен билгеләү, узган хисап чорыннан соң килүче айның 28 числосыннан да соңга калмыйча. Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы үткән салым чоры артыннан килүче елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://mendeleevsk.tatarstan.ru) «Турай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Турай авыл җирлеге Советы
рәисенең урынбасары Р.Р.Шәймөхәммәтов